РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«_23__» _____01_____ 2019 ел** **№ __13___**

Азнакай муниципаль районы буенча торакның бер квадрат метр гомуми мәйданы (сумнарда) бәясе нормативын раслау турында

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында » 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 17 ст., «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында " 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы һәм «Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метр гомуми мәйданының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2018 елның 19 декабрендәге 822/пр номерлы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгын гамәлгә ашыру максатыннан карар чыгарам:

1. Азнакай муниципаль районы буенча 2019 елның I кварталына торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры 46 170 (кырык алты мең йөз җитмеш) сум күләмендә бәя нормативын билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов